КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 10 сентябрь г.Казань № 818

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең бурыч тотрыклылыгын бәяләүне үткәрү кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107[1] статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31[1] статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең бурыч тотрыклылыгын бәяләүне үткәрү кагыйдәләрен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 10 сентябрь, 818 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең
бурыч тотрыклылыгын бәяләүне үткәрү
кагыйдәләре

1. Бу Кагыйдәләр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең бурыч тотрыклылыгын бәяләүне үткәрү тәртибен билгели.

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы ел саен, 30 сентябрьдән соңга калмыйча, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең бурыч тотрыклылыгын түбәндәге күрсәткечләрне кулланып бәяләүне үткәрә:

түләүсез керүләрне һәм (яки) физик затлар керемнәренә салымнан бүлеп алып калынган сумманың өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре керүләрен исәпкә алмыйча, тиешле җирле бюджет керемнәренең гомуми күләменә карата Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычы күләме (К1);

тиешле җирле бюджет чыгымнарының гомуми күләмендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычына хезмәт күрсәтү чыгымнары өлеше (К2) (Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнар күләменнән тыш);

тиешле җирле бюджетның салым һәм салым булмаган керемнәренең һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан дотацияләрнең гомуми күләменә карата, чираттагы финанс елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварыннан соң түләп бетерү вакытлары белән бурыч йөкләмәләрен вакытыннан алда түләп бетерүгә җибәрелә торган түләүләрне исәпкә алмыйча, чираттагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата барлыкка килгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычын түләп бетерү һәм аңа хезмәт күрсәтү буенча түләүләрнең еллык суммасы (К3);

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычының гомуми күләмендә кыска вакытлы бурыч йөкләмәләре өлеше (К4).

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең бурыч тотрыклылыгы күрсәткечләре мәгънәләрен исәпләү методикасы бу Кагыйдәләргә теркәлгән кушымтада китерелгән.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең бурыч тотрыклылыгын бәяләүне үткәрү максатларында, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы җирле бюджетлар үтәлеше турындагы хисаплар, җирле бюджетлар турындагы карарлар, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең муниципаль бурыч кенәгәләре мәгълүматларын һәм башка документларны һәм материалларны (кирәк булганда) файдалана.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең бурыч тотрыклылыгын бәяләүне үткәрү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан заёмга алучыларның түбәндәге төркемнәреннән берсенә кертелә:

а) бурыч тотрыклылыгы югары дәрәҗәдә булган;

б) бурыч тотрыклыгы урта дәрәҗәдә булган;

в) бурыч тотрыклылыгы түбән дәрәҗәдә булган.

5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеген бу Кагыйдәләрнең 4 нче пунктында күрсәтелгән заёмга алучылар төркемнәренә кертү, түбәндәгеләрне исәпкә алып, К1, К2 һәм К3 күрсәткечләре мәгънәләре нигезендә гамәлгә ашырыла:

а) бурыч тотрыклылыгы югары дәрәҗәдә булган заёмга алучылар төркеменә бурыч тотрыклылыгы күрсәткечләренең мәгънәсе түбәндәге чикләрдә булган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге керә:

иң күбе 50 процент – К1 күрсәткече өчен (иң күбе 25 процент – Россия Федерациясе Бюджет кодексының 136 статьясындагы 4 нче пунктында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясындагы 4 нче пунктында каралган чаралар гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге өчен);

иң күбе 5 процент – К2 күрсәткече өчен;

иң күбе 13 процент – К3 күрсәткече өчен;

б) бурыч тотрыклылыгы түбән дәрәҗәдә булган заёмга алучылар төркеменә кимендә ике бурыч тотрыклылыгы күрсәткеченең мәгънәләре түбәндәге дәрәҗәләрдән артып киткән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге керә:

85 процент – К1 күрсәткече өчен (45 процент – Россия Федерациясе Бюджет кодексының 136 статьясындагы 4 нче пунктында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясындагы 4 нче пунктында каралган чаралар гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге өчен);

8 процент – К2 күрсәткече өчен;

18 процент – К3 күрсәткече өчен;

в) бурыч тотрыклылыгы урта дәрәҗәдә булган заёмга алучылар төркеменә бурыч тотрыклылыгы югары яки түбән дәрәҗәдә булган заёмга алучылар төркемнәренә кертелмәгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге керә.

6. Бурыч тотрыклылыгы түбән дәрәҗәдә булган заёмга алучылар төркеменә кергән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге, К1, К2 һәм К3 күрсәткечләренең факттагы мәгънәләренә карамастан, бурыч тотрыклылыгы түбән булган заёмга алучылар төркеменнән чыкканнан соң өч елдан да иртәрәк булмаган вакытта бурыч тотрыклылыгы югары булган заёмга алучылар төркеменә кертелергә мөмкин.

7. Бу Кагыйдәләрнең 4 нче пунктында күрсәтелгән заёмга алучылар төркемнәренә кертелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре исемлеге Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан, агымдагы финанс елының 1 октябреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарыла.

8. К4 күрсәткеченең мәгънәсе 15 проценттан артып киткән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең бурыч йөкләмәләрен рефинанслау рискын киметү максатларында үткәрелә торган бурыч сәясәтенә төзәтмәләр кертү кирәклеге турында тәкъдимнәр җибәрелә.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең бурыч тотрыклылыгын бәяләүне үткәрү кагыйдәләренә кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең
бурыч тотрыклылыгы күрсәткечләре мәгънәләрен исәпләү
методикасы

1. Бу Методика Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең бурыч тотрыклылыгы күрсәткечләре (алга таба – күрсәткеч) мәгънәләрен исәпләү тәртибен билгели.

2. «Түләүсез керүләрне һәм (яки) физик затлар керемнәренә салымнан бүлеп алып калынган сумманың өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре керүләрен исәпкә алмыйча, тиешле җирле бюджет керемнәренең гомуми күләменә карата Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычы күләме» күрсәткече мәгънәсе (К1) күрсәткечләр мәгънәләреннән алынган күрсәткечнең максималь мәгънәсенә тигез итеп алына $К1_{(факт)}$һәм $К1_{(план)}$, шул ук вакытта:

а)$К1_{(факт)}$ түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$К1_{(факт)} = \frac{ДолгОтч_{(факт)}}{Д_{(факт)} - Б_{(факт)}} \times 100,$$

монда:

$К1_{(факт)}$ – төгәлләнгән хисап финанс елы йомгаклары буенча тиешле җирле бюджет үтәлеше турындагы мәгълүматлар (җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап мәгълүматлары) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурыч кенәгәсеннән хисап финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычы турындагы факттагы мәгълүматлар нигезендә исәпләнгән күрсәткеч мәгънәсе;

$ДолгОтч_{(факт)}$ – хисап финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычы күләме;

$Д_{(факт)}$ – физик затлар керемнәренә салымнан бүлеп алып калынган сумманың өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре керүләрен исәпкә алмыйча, хисап финанс елы өчен тиешле җирле бюджет керемнәренең гомуми күләме;

$Б_{(факт)}$ – хисап финанс елы өчен тиешле җирле бюджетка түләүсез керүләр күләме;

а) $К1_{(план)}$ түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$К1_{(план)}=\frac{ДолгТек_{(факт)}}{Д_{(план)} - Б_{(план)}}\times 100,$$

монда:

$К1_{(план)}$– җирле бюджет турындагы карар мәгълүматлары (агымдагы финанс елының 1 августы хәленә карата гамәлдәге редакциядә) буенча агымдагы финанс елына тиешле җирле бюджет күрсәткечләре һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурыч кенәгәсеннән агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычы турындагы фактагы мәгълүматлар нигезендә исәпләнгән күрсәткеч мәгънәсе;

$ДолгТек_{(факт)}$ – агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычы күләме;

$Д_{(план)}$ – физик затлар керемнәренә салымнан бүлеп алып калынган сумманың өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре керүләрен исәпкә алмыйча, агымдагы финанс елына тиешле җирле бюджет керемнәренең гомуми күләме;

$Б_{(план)}$ – агымдагы финанс елына тиешле җирле бюджетка түләүсез керүләр күләме.

3. «Тиешле җирле бюджет чыгымнарының гомуми күләмендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычына хезмәт күрсәтү чыгымнары өлеше (Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнар күләменнән тыш)» күрсәткече мәгънәсе (К2) күрсәткечләр мәгънәләреннән алынган күрсәткечнең максималь мәгънәсенә тигез итеп алына $К2_{(факт)}$һәм $К2_{(план)}$, шул ук вакытта:

а)$К2_{(факт)}$ түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$К2_{(факт)} = \frac{РОбслОбщ_{(факт)}}{Р_{(факт)} - РСубв_{(факт)}} \times 100,$$

монда:

$К2_{(факт)}$– төгәлләнгән хисап финанс елы йомгаклары буенча тиешле җирле бюджет үтәлеше турындагы мәгълүматлар (җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап мәгълүматлары) нигезендә исәпләнгән күрсәткеч мәгънәсе;

$РОбслОбщ_{(факт)}$ – хисап финанс елы өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычына хезмәт күрсәтү чыгымнары күләме;

$Р_{(факт)}$ – хисап финанс елы өчен тиешле җирле бюджет чыгымнарының гомуми күләме;

$РСубв_{(факт)}$ – хисап финанс елы өчен субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган тиешле җирле бюджет чыгымнары күләме. Исәп-хисаплар өчен субвенцияләр исәбенә гамәлгә ашырылган чыгымнарның җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап мәгълүматлары буенча тиешле җирле бюджетка бирелгән субвенцияләр күләменә тигез булуы турында шарт алына;

а) $К2_{(план)}$ түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$К2_{(план)} = \frac{РОбслОбщ_{(план)}}{Р_{(план)} - РСубв_{(план)}} \times 100,$$

монда:

$К2_{(план)}$ – җирле бюджет турындагы карар мәгълүматлары (агымдагы финанс елының 1 августы хәленә карата гамәлдәге редакциядә) буенча агымдагы финанс елына тиешле җирле бюджет күрсәткечләре нигезендә исәпләнгән күрсәткеч мәгънәсе;

$РОбслОбщ_{(план)}$ – агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычына хезмәт күрсәтү чыгымнары күләме;

$Р_{(план)}$ – агымдагы финанс елына тиешле җирле бюджет чыгымнарының гомуми күләме;

$РСубв_{(план)}$ – агымдагы финанс елына субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган тиешле җирле бюджет чыгымнары күләме. Исәп-хисаплар өчен субвенцияләр исәбенә гамәлгә ашырыла торган чыгымнарның җирле бюджет турындагы карар мәгълүматлары буенча тиешле җирле бюджетка бирелә торган субвенцияләр күләменә тигез булуы турында шарт алына;

4. «Тиешле җирле бюджетның салым һәм салым булмаган керемнәренең һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан дотацияләрнең гомуми күләменә карата, чираттагы финанс елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварыннан соң түләп бетерү вакытлары белән бурыч йөкләмәләрен вакытыннан алда түләп бетерүгә җибәрелә торган түләүләрне исәпкә алмыйча, чираттагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата барлыкка килгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычын түләп бетерү һәм аңа хезмәт күрсәтү буенча түләүләрнең еллык суммасы» күрсәткече мәгънәсе (К3) алынган мәгънәләр күрсәткечләренең максималь мәгънәсенә тигез итеп алына $К3_{(факт)}$һәм$К3_{(план)}$ шул ук вакытта:

а) $К3_{(факт)}$ түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$К3_{(факт)} = \frac{РОбсл_{(факт)} + РПог_{(факт)}}{ДНалНенал_{(факт)} + Дот_{(факт)}} \times 100,$$

монда:

$К3_{(факт)}$ – төгәлләнгән хисап финанс елы йомгаклары буенча тиешле җирле бюджет үтәлеше турындагы мәгълүматлар (җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап мәгълүматлары) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурыч кенәгәсе мәгълүматлары нигезендә исәпләнгән күрсәткеч мәгънәсе;

$РОбсл_{(факт)}$ – хисап финанс елы өчен хисап финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата барлыкка килгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычына хезмәт күрсәтү чыгымнарының факттагы күләме;

$РПог_{(факт)}$ – хисап финанс елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварыннан соң түләп бетерү вакытлары белән бурыч йөкләмәләрен вакытыннан алда түләп бетерүгә җибәрелгән түләүләрне исәпкә алмыйча, хисап финанс елы өчен хисап финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата барлыкка килгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычын түләп бетерүнең факттагы күләме;

$ДНалНенал_{(факт)}$ – хисап финанс елы өчен тиешле җирле бюджетның салым һәм салым булмаган керемнәр күләме;

Дот$_{(факт)}$ – хисап финанс елы өчен Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан тиешле җирле бюджетка күчерелгән дотацияләр күләме;

а) КЗ$_{(план)}$түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$КЗ_{(план)} = \frac{РОбсл_{(план)} + РПог_{(план)}}{ДНалНенал_{(план)} + Дот_{(план)}} \times 100,$$

монда:

КЗ$_{(план)}$ – җирле бюджет турындагы карар мәгълүматлары (агымдагы финанс елының 1 августы хәленә карата гамәлдәге редакциядә) буенча агымдагы финанс елына тиешле җирле бюджет күрсәткечләре һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурыч кенәгәсе мәгълүматлары нигезендә исәпләнгән күрсәткеч мәгънәсе;

РОбсл$_{(план)}$ – агымдагы финанс елында агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата барлыкка килгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычына хезмәт күрсәтү чыгымнарының план буенча күләме;

РПог$_{(план)}$ – агымдагы финанс елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварыннан соң түләп бетерү вакытлары белән бурыч йөкләмәләрен вакытыннан алда түләп бетерүгә җибәрелә торган түләүләрне исәпкә алмыйча, агымдагы финанс елында агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата барлыкка килгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычын түләп бетерүнең план буенча күләме;

ДНалНенал$_{(план)}$ – агымдагы финанс елына тиешле җирле бюджетның салым һәм салым булмаган керемнәр күләме;

Дот$_{(план)}$ – агымдагы финанс елына Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан тиешле җирле бюджетка күчерелгән дотацияләр күләме.

5. «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычының гомуми күләмендә кыска вакытлы бурыч йөкләмәләре өлеше» (К4) күрсәткече мәгънәсе Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурыч кенәгәсеннән агымдагы финанс елының 1 гыйнвары, 1 апреле, 1 июле һәм 1 августы хәленә карата бурыч турындагы мәгълүматлар нигезендә түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарылган күрсәткеч мәгънәләреннән алынган күрсәткечнең максималь мәгънәсенә тигез итеп алына:

$$К4_{(т)} = \frac{КрДолг_{(т)}}{Долг_{(т)}} \times 100,$$

монда:

т – агымдагы финанс елының датасы (1 гыйнвар, 1 апрель, 1 июль һәм 1 август);

КрДолг$_{(т)}$ – т датасы хәленә карата Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең кыска вакытлы (бер елдан кимрәк) бурыч йөкләмәләре күләме;

Долг$_{(т)}$ – т датасы хәленә карата Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычы күләме.